| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ ТУЕМБАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТУЕМБАШ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Туембаш

«19» июнь 2023 ел

№ 10

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итүнең Туембаш авыл җирлеге Советының 2022 елның 28 апрелендәге 10 номерлы карары белән расланган Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Туембаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарә сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итүнең Туембаш авыл җирлеге Советының карары белән расланган Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне

кертергә:

3 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) (алга таба – Татарстан Республикасы Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

4 нче пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

5 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга;

6 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга.

7 пунктның беренче һәм өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга.

11 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы И.Ф. Гарипов